# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлеге составына керүче Зичәбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 19 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: "Сез 2021 елда Дурт-Мунча авыл җирлегенең Зичәбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- чишмәне төзекләндерү;
- зиратка капка кую.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 83 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 58 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 48 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 10 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлегенең Зичәбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Түбәндәге сорау буенча карар кабул итәргә: «Сез 2021 елда Дурт-Мунча авыл җирлегенең Зичәбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:
- чишмәне төзекләндерү;
- зиратка капка кую" кабул ителгән.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Дурт-Мунча авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Р.Т.Ситдиков